СОВЕТ СРЕДНЕКИРМЕНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ МАМАДЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Ленина, д.16А, с. Средние Кирмени, Мамадышский район, Республика Татарстан, 422171

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ УРТА КИРМӘН АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
Ленин ур., 16А нчы йорт, Урта Кирмән авылы, Мамадыш районы, Татарстан Республикасы,422171

тел.(факс): (85563) 2-92-38;2-92-44 e-mail: Skimer.Mam@tatar.ru, www:mamadysh.tatarstan.ru

Решение | Карар
--- | ---

| | |
|---|---|
| Решение | Карар |
| № 4-35 | 15 апрель, 2024 ел |

Татарстан Республикасы
Мамадыш муниципаль районы
Урта Кирмән авыл җирлегенең җирле
әһәмияттәге аерым мәсьәләләрен
хәл итү вәкаләтләренең бер өлешен
тапшыру турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясының 4 өлеше, «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Урта Кирмән авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Урта Кирмән авыл җирлеге Советы КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Советына Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитетына җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча Урта Кирмән авыл җирлеге Башкарма комитетының түбәндәге вәкаләтләрен тапшыру турындагы мәсьәләне карарга тәкъдим итәргә:
җирләү эше мәсьәләләре буенча махсуслаштырылган хезмәт булдыру һәм аның эшчәнлеге тәртибен раслау;
гарантияләнгән җирләү хезмәтләре исемлеге буенча күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясен билгеләү.
2. Мамадыш муниципаль районы Советы тарафыннан әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән тәкъдим кабул ителгән очракта, Урта Кирмән авыл җирлеге башкарма комитетына:
Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитеты белән әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән вәкаләтләрне тапшыру турында килешү төзергә;
Әлеге карарны гамәлгә ашыруны тәэмин итү максатларында Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының Урта Кирмән авыл

җирлеге советы карары проектын 2024 елга һәм 2025 һәм 2026 еллар план чорына Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының Урта Кирмән авыл җирлеге бюджеты турындагы карарга үзгәрешләр кертү хакында бюджет законнары нигезендә эшләргә һәм карауга тәкъдим итәргә.

3. Әлеге карарны авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Мамадыш муниципаль районы рәсми сайтында, "Интернет" мәгълүмати-коммуникацион челтәрендәге Татарстан Республикасының муниципаль берәмлекләр Порталында http://mamadysh.tatarstan.ru/ веб- адресы буенча һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo. tatarstan.ru) игълан итәргә.

4. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Мамадыш муниципаль районының Урта Кирмән авыл җирлеге башлыгы Б.Ф.Хасановка йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Мамадыш муниципаль районы
Урта Кирмән авыл җирлеге башлыгы,
авыл җирлеге Советы рәисе /Б.Ф.Хасанов/